Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы арасында вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру турында 2018 елның 10 гыйнварындагы өстәмә килешү

Чистай шәһәре «30» ____12_____2021 ел

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты, алга таба «Җирлек» дип аталучы, җитәкче Рәхимов Илдар Фаил улы йөзеннән, «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче, бер яктан, һәм Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы, алга таба «Палата» дип аталучы, җитәкче Исхакова Марина Юрьевна йөзеннән, Палата турында Нигезләмә нигезендә эш итүче, икенче яктан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының 2021 елның 16 декабрендәге 11/8 номерлы карары, Чистай муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 12/8 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы арасында вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру турында 2018 елның 10 гыйнварындагы өстәмә килешү төзеделәр:

1. Килешүнең 1.1 пунктына үзгәрешләр кертергә, абзац белән тулыландырырга:

«Әлеге килешү буенча җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырыла.».

2. Әлеге өстәмә килешү Яклар кул куйганнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге өстәмә килешү бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә төзелгән.

Якларның адреслары һәм реквизитлары:

| | |
|---|---|
| ТР Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы |
| 422971, Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, К.Маркс ур., 46-нчы йорт | 422980, Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Энгельс ур., 152А |
| ИНН 1652011790, КПП 165201001 | ИНН 1652011737, КПП165201001 |
| Җитәкче____________И.Ф.Рәхимов | Җитәкче __________М.Ю.Исхакова |